МӨҺИМ ВАКЫЙГА
Россия Президентын сайлауга кагылышлы төп сорауларга җавап бирәбез
> 2

КЕМНӘРГӘ КАГЫЛА?
Яңа кабул ителгән республика законнары нинди үзгәрешләр алып килә?
> 5

УН ХОЛЫК
Күп бала анасы Кәүсәрия Исмәгыйлева бала тәрбияләү серләре белән бүлеште
> 6

ПӘРДӘ АЧЫЛА
«ВТ» хәбәрчесе Камал театрының сәхнә арты хәлләрен белешеп кайтты
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 29 (29189) | Чәршәмбе | 6 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:
«НИГЕЗ – АВЫЛДА, АВЫЛНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ – ЭШМӘКӘРДӘ»

Таяну ноктасы

Кичә Россиянең 40 төбәгеннән килгән 800 кеше бер мәйданда очрашты. XII Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенының икенче көнендә делегатлар пленар утырышка җыелды.

Елдагыча, «Корстон» мәдәни-күңел ачу үзәгенең фойесында оештырылган күргәзмә-ярминкәдә Россиянең төрле төбәкләрендә җитештерелгән азык-төлек, милли киемнәр, сувенирлар тәкъдим ителгән иде. Алар арасында һәркем күңеленә хуш килгәнне сайлап алырга, фикерләшергә-киңәшергә мөмкинлек тапты. Билгеле инде, күчтәнәчләр алырга теләүчеләр дә күп иде. Кемдер Оренбург шәлләрен сайлады, кемдер милли киемнәр янына тукталды, кемдер тәмле чәйләр, казылыклар, бал продукциясен тәмләп карады.

Матбугат вәкилләре белән очрашуда Мөслим районын татар авылы яшәеше моделенә иң нык туры килүче район дип билгеләп узганнар иде. Күрәсең, шуңадыр, районга һәм бигрәк тә казны бренд буларак күтәрүгә күргәзмәдә зур игътибар күрсәтелгән иде. Казлары, мендәрләре, шифалы майлары, шул эчтәлеккә туры килүче китапчыклар – барысы да бар.

– Әлеге мендәрләр «Каз өмәсе» бәйрәме кысасында узган бәйгедә беренче урынны алган иде, – дип таныштырды чигүле мендәрләр белән Индира Хәмәдишина. – Боларда каз рәсеме сурәтләнгән. Алар мендәрләрдә генә түгел, тастымалларга да, алъяпкычларга да кергән.

Башкортстанның Октябрьск шәһәрендә тегелә торган «Орион» милли киемнәре янында да халык шактый күп җыелган иде.

– Без сыйфатка эшлибез. Һәр киемнең тарихын өйрәнәбез, музейлардан белешәбез. Россиянең зур шәһәрләрендәге, башка илләрдәге иҗат коллективлары без теккән милли киемнәрдән чыгыш ясый. Бик затлы өс киемнәрен көндәлек тормышта кияргә алмыйлар, билгеле. Ә менә алъяпкыч, изү, калфак һәм түбәтәй бик күп сатыла. Шулай ук хатын-кызлар күлмәкләрен дә бик теләп алалар. 26 ел инде миллилеккә йөз тотып эшлибез, соңгы елларда халык арасында ихтыяҗ артуын нык тоябыз. Бу бигрәк тә Казанга килгәч сизелә. Бик яратам бу шәһәрне, – диде бренд җитәкчесе Сиринә Мөслихова.

Башкортстаннан тагын бер кунак – Миякә районыннан килгән Ләйсән исә һәр кунакны тәмле чәйләре белән сыйларга тырышты. Янына җыелган һәркемгә игътибар күрсәтеп: «Бу чәй сезгә көч, шифа, энергия бирсен», – дип, матур теләкләрен дә кызганмады.

tatarstan.ru

Әлбәттә, без дә бу мөлаем ханым яныннан тыныч кына узып китә алмадык.

– Күргәзмәдә беренче тапкыр катнашуым. Килгәнемә сөенеп туя алмыйм, – диде ул. – Мин – Зәйнәп исемле данлыклы үләнче әбиемнең эшен дәвам иттерүче. Аның шифасы бик күп кешеләргә тиде. Әбием гел: «Бөтен дару – безнең аяк астында. Файдалана, эчә генә белергә кирәк», – дип әйтә иде. Хәзер безнең буын пакетлы чәйләргә күчеп бара. Ләкин бу үләннәрне яратып кулланганда, файдасы әйтеп бетергесез зур. Әбиемнән алынган белемнәрне балаларыма тапшырасым килә. Хәзер инде миңа улым белән кызым да, 90 яшьтән өлкән әбием дә ярдәм итә. Бергәләп җыйган үләннәр белән никадәрле кешене сыйлый алуыма шатланам мин. Аларны киптереп, махсус пакетларга тутырып, кешеләргә тәкъдим итәбез.

«Күршеләр бай булса, тавыклар тук була»

Пленар утырыш башланганчы, әлеге күргәзмәне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карап чыкты. Шуннан соң чараның рәсми өлеше башланды.

Әстерхан өлкәсе Идел буе районының Яр-Түбә авылы башлыгы Фаил Бердиевның чыгышы иң күңелгә тия торганы булгандыр. Залда утыручыларның игътибарын эшләгән эшләренең нәтиҗәсеннән бигрәк көчле, намуслы егет тәрбияләве белән җәлеп итте ул. Аның улы Азамат Бердиев хәрби операциядә каты яраланып, госпитальгә эләгә. Табиблар сугышка кире кермәскә киңәш итсә дә, яудагы иптәшләрен калдырасы килми, алар янына ашыга. Узган елның май аенда исә бик каты яралана, ярдәмгә ашыккан иптәшләренә: «Егетләр, мин инде терелә алмыйм. Машинада урыннар аз, мине монда калдырыгыз, башкаларны алыгыз», – дип, яраланган җирендә ятып кала һәм һәлак була. Аны яу кырыннан 4 көннән генә алып чыгалар. Үлгәннән соң, Батырлык ордены белән бүләкләнә. Ә барлык офицерлар һәм солдатлар ныклап сорагач, аңа Россия Герое исеме бирелә.

Әти кешенең: «Балам Азамат Казанны, Татарстанны бик яратты. Госпитальдә ятып чыкканнан соң да, берничә көн генә узуга ук, Казанга китте. Улым юк инде, аның өчен мин әйтәм: «Россиягә хезмәт итәм! ВДВга дан!» – дигән сүзләреннән соң залда утырган бар халык, аягүрә басып, алкышларга күмде.

Ахыры 5 нче биттә >

Ике тапкыр чистарталар

Быел «Татарстанның чиста урманнары» чарасы ике тапкыр уздырылачак. Беренчесе – 22 апрельдән 22 июньгә, ә икенче тапкыр – 9 сентябрьдән 9 ноябрьгә кадәр.

Республика Хөкүмәте боерыгыннан күренгәнчә, чараны үткәрүгә җаваплы итеп Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы билгеләнгән. Ул, биләмәләрдән файдаланучылар белән берлектә, урманнарны чүп-чардан, чыбык-чабыктан арындыру, чатырларны, мәгълүмат такталарын төзәтү-төзекләндерү эшләрен оештырачак.

Игътибарлы бул!

Ел башыннан бирле республикада җәяүлеләрне бәрдерүнең 121 очрагы теркәлгән. 10 кешенең гомере өзелгән, 113е зыян күргән. Фаҗигаләрнең күпчелеге төнлә яки кичен караңгы төшкәч килеп чыккан. Һәлак булган җәяүлеләрнең киемендә караңгыда «янып» торган элементлары булмаган.

Дәүләт автомобиль инспекциясе хезмәткәрләре 4 марттан машина йөртүчеләрнең җәяүлеләргә юл бирмәү очракларын булдырмау эшен көчәйткән. Алар шулай ук караңгы вакытта шәһәр-авыллар читендәге юллар аша чыгучы җәяүлеләр киеменең «янып» тору-тормавын тикшерә.

Чара 13 мартка кадәр дәвам итәчәк. Дәүләт автомобиль инспекциясе шуны искә төшермәкче: йөртүчеләр юлда җәяүлеләр сукмагына килеп җитәрәк машинасының тизлеген киметергә тиеш. Җәяүлеләрдән исә юл аша бары тик кичүләрдән генә чыгу таләп ителә. Әле анда да юлдан килүче транспортның туктап каласына инангач кына чыгып китәргә кирәк.

Күбрәк эшли башлаганнар

Узган елда Россиядә эш көненең уртача озынлыгы буенча рекорд куелган. «РБК» хәбәренә караганда, ул алдагы елдагыдан 0,9 процентка артып, 7,17 сәгать тәшкил иткән. Соңгы 19 елда иң зур күрсәткеч бу.

Эш вакыты бер хезмәткәргә 1 ел эчендә 17,3 сәгатькә артып, елына 1,77 мең сәгатькә җиткән. Шулай итеп, эш көне озынлыгы бер ел өчен дә, бер көн өчен дә рекорд куйган (статистика 2005 елдан бирле алып барыла). Алдагы рекорд пандемиягә кадәр – 2019 елда теркәлгән. Ул чагында эш көненең уртача озынлыгы 7,15 сәгать тәшкил иткән, ә бер хезмәткәр бер ел эчендә 1,76 мең сәгать эшләгән.

Узган елда балыкчылык өлкәсе хезмәткәрләренең эш көне иң озыны булган. Алар уртача 8,21 сәгать эшләгән. Икенче урында – администраторлар (7,61 сәгать). Тимер рудасы чыгару өлкәсендә эшләүчеләр (7,6 сәгать) өченче урында.

Көн кадагында

Мөгаллимгә – ташлама

Россиядә укытучылар өчен ташламалы ипотека пәйда булырга мөмкин. Илнең Мәгърифәт министрлыгы шундый тәкъдим белән чыккан. Бу яңалык яшь укытучыларга кагыла. Проект авторлары шул рәвешле укытучы һөнәренең абруен арттырып, мәктәпләрдәге мөгаллимнәргә кытлыкны киметмәкче.

Рәсми саннардан күренгәнчә, 2022–2023 уку елында Россия мәктәпләрендә 198 мең укытучыны эшкә алганнар. Шул ук вакытта шушы чорда 193,5 мең укытучы эштән киткән. Күбесе үз теләге белән. Проект авторларының берсе Россия Дәүләт Думасының мәгърифәт комитеты рәисенең беренче урынбасары Яна Лантратова фикеренчә, укытучылар өчен махсус ташламалы ипотека кертелә калса, вазгыять шактый яхшырачак.

– Утыз яше тулмаган һәм мәктәптә кимендә бер ел эшләгән яшь укытучыларга 30 елга кадәр 2 процентлы ташламалы ипотека бирә башларга кирәк. Бу яңалык тулы ставкада эшләгән яшь укытучыларга кагылачак, – дип ачыклык керткән Лантратова.

Хәзерге вакытта Мәгърифәт министрлыгы каршындагы эш төркемендә бу уңайдан фикер алышулар бара. Ноябрьдә исә бу тәкъдимне Дәүләт Думасына кертергә җыеналар.

Мамадыш районының Дүсмәт авылы мәктәбендә инглиз теле укытучы Айсинә Шәрифуллина, бу яңалыкны ишеткәч, бик шатланган. КФУның Алабугадагы филиалын тәмамлап, районга эшкә кайткан яшь белгеч ул. Авыл мәктәбендә эшли башлавына – ярты ел.

– Яшь укытучыларга ташламалы ипотека бирә башласалар, бик теләп алыр идек. Әле бу көннәрдә генә, ипотека ала калсак дип, шартларын белешкән идек. Процент ставкалары янына якын килерлек түгел. Бюджет системасында эшләүчеләргә – 16–17, башкаларга 20–22 процентлы ипотека бирәләр. Болар янында 2 процент чүп кенә бит. Ташламалы ипотека яшь белгечләргә бик яхшы мотивация булыр иде, – ди яшь белгеч.

Әлмәт районының Яңа Нәдер авылында башлангыч сыйныфлар укытучысы Айгөл Әхмәдуллина, бу яңалык барлык укытучыларга да кагылса яхшы булыр иде, дип саный. Бүгенге вазгыятьтә ташламалы ипотека алу мөмкинлеге яшьләр өчен генә түгел, тәҗрибәле белгечләргә дә комачауламый.

– Ташламалы ипотека мәктәптә озак еллар эшләгән тәҗрибәле укытучыларга да бирелсен иде. Күпьеллык хезмәтнең тагын бер әҗере булыр иде ул. Яшь белгечләргә дә зур стимул булыр, билгеле. Үз эшен яраткан белгеч барыбер үз һөнәрендә кала ул. Шөкер, үзебездә дә андый яшь белгечләр бар. Әмма ниндидер өстәмә программалар булса, үз һөнәренә тугры калучылар саны тагын да артыр иде, – ди егерме биш ел гомерен балалар укытуга багышлаган тәҗрибәле укытучы.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

2024
гаилә елы

Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы:

Гаилә – һәркем өчен иң кадерле урын. Монда бер-беребезне яратырга һәм хөрмәт итәргә өйрәнәбез, якыннарыбыз һәм туганнарыбыз турында кайгыртабыз, авырлыкларны җиңеп чыгарга көч табабыз, шатлыкларны уртаклашып яшибез.

РОССИЯДӘ – ТЕРЛЕКЧЕЛЕК

2023 ел азагына терлек саны (млн)

ДУҢГЫЗ >>	28,2
БӘРӘН ҺӘМ САРЫК >>	20,3
МӨГЕЗЛЕ ЭРЕ ТЕРЛЕК >>	17,1

**Росстат мәгълүматлары буенча*

Парклы җиһан

Республикада 2015–2023 елларда барлыгы 398 парк-сквер булдырылган яки төзекләндерелгән. Татарстан шәһәрләрен үстерү институты директоры Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, парк-скверлар бигрәк тә Казанда күп төзелгән (44). Икенче урында – Түбән Кама районы (26), Яшел Үзән (21) – өченче. Бөгелмә районында – 17, Чаллы – 16, Азнакай – 14 һәм Питрәч районында 11 иҗтимагый киңлек пәйда булган яки төзекләндерелгән.

Тугыз елда бу максатка барлыгы 22 миллиард сум чамасы акча тотылган. Шуның 13,7 миллиарды – Татарстан казнасыннан, 8 миллиарды – федераль казнадан, 2,8 миллиарды – төрле федераль бәйгеләрдә җиңүдән кергән акча.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТРАМП КАЛА

Глобаль икътисадтагы проблемаларның кискенләгән, ОПЕК+ илләре нефть чыгаруны киметү турында яңадан карар кабул иткәннән соң, кара алтын бәяләренең сизелерлек өскә сикермәве дә дәлилли. Гадәттә андый карардан соң фьючерслар кискен кыйммәтләнә иде. Бу юлы «Брент» аз гына бәя күтәрде дә яңадан элекке хәлгә кайтты.

Ә бит картель нефть чыгаруны өстәмә рәвештә тагын 2,2 миллион баррельгә киметә. Хәзер ОПЕК+ бәянең түбән төшмәвен уңыш дип саный инде. Башка елларда кара алтынны күпләп Кытай сатып ала һәм нефть чыгаручы илләр шуннан файда күрә иде. Быел аларда да чималга ихтыяҗ артмый. Пекиндагыларның үз хәле хәл: тагын бер иң эре төзелеш компаниясе Vanke банкротлык чигендә, аның акцияләре, 7,13 процентка очсызланып, тарихи минимумда бәяләнә. Төзелеш тармагын коткару өчен, хөкүмәт гадәттән тыш күп акча тотты, әмма булышмый. Җитмәсә, хәрби бюджетны рекордлы рәвештә үстерергә туры килә. Оборона бюджеты эчке тулай продуктны узып үсә: 2024 елда, 7,2 процентка артып, 231 миллиард долларга җитте. Кытайлар протест акцияләренә ешрак чыга башлаган, дигән хәбәрләр дә килә.

АКШта сайлау алды кампаниясе кыза. Праймеризларда Трамп ышанычлы рәвештә җиңеп килә. Республикачылар арасында аның төп көндәше Никки Хейли бары тик Вашингтонда гына (Колумбия округы) җиңүгә иреште. Ноябрь сайлавында бюллетеньдә Трамп фамилиясе торачагына хәзер берәү дә шикләнми. Сайлауда җиңү шансы да зур. Трампның җиңүеннән Америкада гына түгел, Европада да куркалар. НАТОны таркатыр дигән хәвеф бар. Трамп сайлау алды кампаниясендә сискәндерерлек белдерүләрне бер генә тапкыр ясамады. Әйтик, 2001 елда Бөтендөнья сәүдә үзәген Америка үзе шартлатуын әйтте. Президент чакта моны игълан иттермичә, телен тешләтеп торуларын да яшермәде. Башка сенсацияле фактларны өскә тартып чыгарудан да курыкмады. Бульдозер кебек алга юл ярып баручы кандидатның җиңүеннән котылуның бер генә юлы бар – аның исемен бюллетеньгә кертми калдыру. Әмма АКШның Югары суды бу мөмкинлекне үз карары белән юкка чыгарды. Трампны исемлектән төшереп калдыру вәкаләтенә бары тик Конгресс кына ия дип табылды. Трамп социаль челтәрләрдә моны «Америка өчен зур җиңү» дип бәяләде.

Дөнья икътисадындагы турбулентлыкны биткоин курсының кискен үсеше дә дәлилли. Дүшәмбе кичендә аның бәясе, тарихи максимумга җитеп, 69 мең доллардан ашып китте. Бу санга алданырга ярамый. 2021 елның ноябрендә криптотәңкә бер тапкыр шулай югары бәяләнгән иде инде. 2022 ел октябрендә куык 15 мең 880 долларга кадәр шиңде.

Россиядә

ЗЫЯННЫҢ ФАЙДАСЫ ЮК

Россия икътисадының санкцияләргә бирешмичә нык торуын «дошман» илләрдә дә таныйлар. Санкцияләр масштаблы кертелде, әмма әлегә кадәр үтәлешләре генә «ташка үлчим» дип әйтерлек. Хәтта дус булмаган илләр бизнесы да Мәскәүгә чикләүләрне әйләнеп үтәргә булыша. Бизнесның табигате шундый: аны сәясәт тә, хәрби конфликтлар да түгел, табыш кызыксындыра. The Economist басмасы Россиягә санкцияләрдән котылырга булышучы төп илләр дип Польша белән Балтыйк буе илләрен атый, мәсәлән.

Росстат мәгълүматлары, чикләүләр нәтиҗәсендә ил сәнәгате 2022 елдан соң икътисадый күтәрелеш мәйданы булды, дип раслый. Зур технологияләр таләп итмәгән тармакларда импортны алыштыру уңышлы барды. Әмма статистика 2023 ел маеннан соң сәнәгатьнең эчке тулай продуктны үстерү потенциалы югала башлавын күрсәтә. Үткән елның маеннан алып быелның гыйнварына кадәр үсеш булмаган диярлек. Файдалы казылмалар чыгару 1,7 процентка кимегән, эшкәртү тармагы 0,8 процентка гына үскән. Белгечләр хәрби сәнәгать комплексының югары технологияләргә бәйле тармагы көчле үсештә дип саный, әмма бу тармак статистикасы яшерен. 2022 ел гыйнвары белән чагыштырганда быелның гыйнварына компьютерлар, электрон һәм оптик җайланмалар эшләү – 70, транспорт чаралары һәм җиһазлары (калканлы техниканы да исәпкә алып) – 48,8, күн һәм күн эшләнмәләр ясау 32,2 процентка үскән.

Ләкин эшкәртү тармагының 40 процентын тәшкил итүче төп өлкәләрдә түбәнәю күзәтелә. Металлургиядә җитештерү – 3,6, нефть продуктлары җитештерү – 3,9, химия продуктлары 1,1 процентка кимегән. Автомобильләр җитештерү 30,3 процентлык кискен түбәнәюдә. Агач эшкәртү – 14, машиналар һәм җиһазлар җитештерү 6,3 процентка кимегән.

Быелның икенче кварталыннан Россия тагын нефть чыгаруны һәм аның экспортын тәүлеккә 471 мең баррельгә киметә. Дөнья базарында кара алтын ярыйсы гына кыйммәт йөрсә дә, Urals маркасы 17 долларга арзангарак сатыла. Февральдә, мәсәлән, котировка баррельгә 66 доллар йөргән. 2024 ел бюджетына баррель бәясе 71,3 доллар булыр дип тәгаенләнгән. Әмма хөкүмәттә бәянең түбәнрәк булуыннан курыкмыйлар. Сумның курсын түбәнәйтү нефтьнең сумнардагы бәясен тиешле югарылыкта тотачак.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ДУСЛАР ҖЫЕЛГАН ҖИРДӘ

«Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме берләштерүче халыкара иҗтимагый мәйдан булып тора. Бу хакта Татарстан Рәисе – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Ислам хезмәттәшлеге оешмасы әгъзалары – дәүләт илчеләре белән очрашуда әйтте. Чарада Россия чит ил эшләре министры урынбасары Андрей Руденко да катнашты.

– Бүгенге гадәти булмаган вакытта, халыкара мөнәсәбәтләр кризис кичергән шартларда безнең хезмәттәшлек аерым әһәмияткә ия, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Быел мөселман дәүләтләренең иң зур һәм йогынтылы халыкара берләшмәсе булган Ислам хезмәттәшлеге илләре оешмасына 55 ел тула. 2005 елдан бирле Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә илебез Ислам хезмәттәшлеге илләре оешмасында күзәтүче булып тора. Мөселман илләре белән хезмәттәшлекне киңәйтү – Россия тышкы сәясәтенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе.

Татарстан Рәисе билгеләп үткәнчә, Россияне дустанә мөнәсәбәттәге Ислам дөньясы дәүләтләре белән тигез хокуклы диалог һәм хезмәттәшлек нигезендә якынаюга ярдәм итү омтылышы гына түгел, ә төрле юнәлешләр буенча хезмәттәшлекне киңәйтүгә, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгытуга, мәдәни күптөрлелекне һәм цивилизацияләр диалогын үстерүгә юнәлеш бирү дә берләштерә.

> **«Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме берләштерүче халыкара иҗтимагый мәйдан булып тора.**

2023 елда Швеция һәм Даниядә Коръән яндыру акцияләре ислам дөньясында ачу хисе дулкыны тудырды һәм Россиядә катгый рәвештә гаепләнде, дип тә ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. «Безнең ил Президенты Владимир Путин мондый гамәлләрне җинаять дип атады. Рус православие чиркәвендә моны мөмкин булмаган вандализм дип бәяләделәр. Россия мөселманнарының рухи лидерлары да шундый ук мөнәсәбәт белдерде. Моннан тыш, Россиядә Якын Көнчыгыштагы хәлләрнең кискенләшүе, Газзә секторындагы канкойгыч сугышлар, күпсанлы корбаннар һәм гуманитар катастрофа өчен дә борчылалар. 2023 елның 12 октябрендә тәүге аңлатмада ук без «Россия – Ислам дөньясы» төркеме тигезлек, гаделлек һәм хөрмәт принципларына, халыкларның мәдәни-цивилизацияле үзенчәлегенә таяна дип белдердек, – диде ул. – Фәләстыйн – Израиль конфликты мәсьәләләрендә төркем җитәкчелеге Россия Президенты белдергән позициядә тора. Безнең ил һәрвакыт БМОның Иминлек Советы карарларын үтәүне яклый».

Рөстәм Миңнеханов май аенда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумына да аерым тукталды. Россия Президенты карары нигезендә җыенга федераль статус бирелде. 2023 елда форумда дөньяның 80 иленнән һәм Россиянең 86 төбәгеннән 16 меңнән артык кеше катнашты. Рөстәм Миңнеханов барысын да форумга чакырды.

Моннан тыш, 2022 елда Казан Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы статусын да алды. Ел саен августта Казан глобаль яшьләр саммиты үткәрелә. Ә 2025 елда Казанда федераль хакимият органнары һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы ярдәме белән беренче ислам яшүсмерләр уеннарын уздыру каралган.

– Казанда киң колачлы «Киләчәк уеннары» тәмамланды. Мондый форматның Россиядә уйлап чыгарылуы сөендерә. Казанда Уеннарны ачу тантанасында Россия Президенты Владимир Путин, БДБ дәүләтләренең күп кенә башлыклары, шулай ук Кытай, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Куба, Төркия, Индонезия кебек илләрдән югары делегацияләр катнашты, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Быел Татарстанда узачак тагын бер мөһим чара – БРИКС саммиты. «Анда катнашу өчен Казанга утызлап чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмалар, шул исәптән мөселман дәүләтләре башлыклары килер дип көтелә, – диде Татарстан Рәисе. – Шулай ук 2024 елның июнендә Казанда БРИКС илләре уеннары узачак. Кадерле дуслар! Бүгенге очрашу барышында без эшебезнең нәтиҗәләре турында фикер алышуны дәвам иттерәчәкбез, алда торган эшләр турында сөйләшәчәкбез. Сезне Татарстанда күрүебезгә һәрвакыт шат булырбыз. Форумда гына түгел, теләсә кайсы вакытта да Татарстанга рәхим итегез».

Әлеге чарага кадәр Рөстәм Миңнеханов Бәһрәйн Әмире белән дә очрашкан иде. Очрашу Бәһрәйн башкаласы Манамада узды, анда Татарстан Рәисе варис шаһзадә чакыруы буенча барды. Бәһрәйн Әмире Хәмәд ибн Иса Әл-Хәлифә Россия – Бәһрәйн мөнәсәбәтләре кысасында Татарстан белән хезмәттәшлекнең мөһимлеген билгеләп үтте. Әңгәмә барышында Бәһрәйнгә хәләл стандартлары буенча җитештерелгән Татарстан продукциясен озатуга бәйле килешүгә ирештеләр. Рөстәм Миңнеханов Бәһрәйн делегациясен «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»га да чакырды.

tatarstan.ru

ЫШАНЫЧЛЫ КҮРШЕЛӘР

Рәсми Татарстан

Татарстан тәҗрибәсе, хезмәттәшлекне ныгыту һәм «Киләчәк уеннары»ннан соң калган тәэсирләр. Республика башкаласына ике көнлек эш визиты белән Казахстан Парламенты Мәҗлесе Рәисе Ерлан Кошанов җитәкчелегендәге делегация килде.

Татарстан башкаласында Казахстан Парламенты Мәҗлесе Рәисе иң элек Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашты. Кунакны сәламләп, Рөстәм Миңнеханов Россия – Казахстан мөнәсәбәтләре кысасында Казахстан белән Татарстан арасында үзара хезмәттәшлекне ныгытуның әһәмияте турында әйтте. Ул шулай ук күптән түгел генә Казахстан Президенты Касыйм-Җомарт Токаевның Казанга килүен һәм «Киләчәк уеннары» халыкара турнирының ачылыш тантанасында катнашуын да искә алды.

– Соңгы елларда Казахстан белән хезмәттәшлек дәрәҗәсе шактый үсте, – диде Рөстәм Миңнеханов.

2023 елның тугыз ае нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Татарстан белән Казахстан арасындагы товар әйләнеше, 37 процентка артып, 652 миллион долларга җиткән.

– Казахстан Президентының җылы сәламләү сүзләрен җиткерәм, – диде Ерлан Кошанов. – Ул күптән түгел Казанга килүе һәм «Киләчәк уеннары»ның ачылыш тантанасында алган тәэсирләре белән уртаклашты. Президент билгеләп үткәнчә, спорт, фән һәм технологияләрне берләштерү – бик үзенчәлекле карар.

Очрашу барышында яклар хезмәттәшлекне үстерү мөмкинлекләре турында фикер алышты.

Казахстан Парламенты Мәҗлесе делегациясе республиканың мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге мөмкинлекләре белән дә танышты. Әлеге чараларда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Аерым алганда, кунаклар Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркта, «Школа 21» белем бирү киңлегендә булды. Парламент вәкилләре «Химград» технополисының сәнәгать мәйданнарын карады.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Казахстан Парламенты Мәҗлесе Рәисе Ерлан Кошанов белән очрашуда да хезмәттәшлекне ныгыту турында сөйләштеләр.

– Казахстан – безнең республика өчен аерым әһәмияткә ия булган хезмәттәш, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Сәүдә өлкәсендәге элемтәләр актив рәвештә үсә, соңгы ун елда Казахстан традицион рәвештә Татарстанның төп тышкы сәүдә хезмәттәшләре унлыгына керә. Шуңа күрә Казахстан парламенты делегациясенең республикага килүенә бик зур әһәмият бирәбез.

Фәрит Мөхәммәтшин Казахстан һәм Татарстан арасындагы гуманитар элемтәләргә дә аерым тукталды. Аның әйтүенчә, Татарстанда ике меңнән артык казах яши. Бездә казах милли-мәдәни берлеге эшли. Ә Казахстанда яшәүче татарлар – 205 меңгә якын. Фәрит Мөхәммәтшин, читтәге татар җәмәгатьчелегенә ярдәм күрсәтүләре өчен, Казахстан парламенты вәкилләренә һәм җитәкчелеккә рәхмәт әйтте.

Ерлан Кошанов, үз чиратында, республика парламентында җылы кабул итүләре өчен рәхмәт әйтте:

– Татарстанга эш визиты программасы бик тыгыз: кыска гына вакыт арасында безнең делегация югары технологияләр өлкәсендәге заманча предприятиеләрдә булырга да, Казан Кремленең мәдәни объектлары белән танышырга да өлгерде. Татарстан безнең өчен икътисадның барлык өлкәләрендә дә алга таба хәрәкәт итү һәм милләтара тынычлыкны ныгыту үрнәге булып тора.

Ерлан Кошанов республика делегациясен Казахстанга кунакка да чакырды. «Безнең өчен парламентара мөнәсәбәтләрне ныгыту мөһим. Өстәвенә бүген безнең парламентлар гаилә, аналарны һәм балачакны яклау, фән һәм мәгарифне, инфраструктураны үстерү кебек юнәлешләрдә охшаш закон проектлары буенча эшли», – диде ул. Татарстанның мәгълүмат технологияләрен үстерү юнәлешендәге тәҗрибәсенә аерым тукталып: «Без Казахстанны IT дәүләткә әйләндерү турында сөйлибез. Шуңа күрә сезнең бу өлкәдәге тәҗрибәгез бик кызык», – диде.

АЧЫК һӘМ АҢЛАЕШЛЫ

БЕЛГЕЧЛӘР ХАЛЫКНЫҢ САЙЛАУГА БӘЙЛЕ СОРАУЛАРЫНА ҖАВАП БИРДЕ

2024 15–17 МАРТ РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУЛАР

БЕРДӘМЛЕКТӘ КӨЧ – РОССИЯ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРӘБЕЗ!

ЦИК.РФ

Сайлауга бару ни өчен бик мөһим? Күзәтүче булсаң, түлиләрме? Мәгълүмати һөҗүмнән, ялган хәбәрләрдән ничек сакланырга? «Минем тавыш» онлайн форумында әнә шул һәм башка сорауларга җавап табарга мөмкин иде.

Татарстанның Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев әйтүенчә, республикада бу форумның дүртенчесе уза инде.

– Ике төп максатны күздә тотабыз: тавыш бирергә җыенучыларга мәгълүмат ирештерү, аларның сорауларына җавап бирү һәм сайлауга чакыру, – диде Андрей Кондратьев.

«Бөтен дөнья күзәтә»

Россиягә бөтен дөньяның күзләре төбәлгән. Россия Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов сүзләренчә, 15–17 март көннәрендә буласы сәяси вакыйгаларны бигрәк тә игътибар белән күзәтәчәкләр.

– Минем төрле елларда һәм төрле дәрәҗәдәге сайлау кампанияләрендә катнашканым бар. Без, нинди генә вазгыять булса да, аларны иң мөһиме дип кабул итәргә күнеккән. Әмма быелгысы чын мәгънәсендә мөһим булачак, – диде депутат. – Хәзерге вакытта бөтен дөнья бик зур үзгәрешләр чорында яши. Кешелек дөрес, яңа, гаделрәк тәртип көтә. Шулай килеп чыкты инде: бу катлаулы процессның алгы рәтендә – тагын безнең ил. Шуңа күрә барысы да безнең илгә карап тора, барысы да тагын бер кат Россия бу сорауларга ничек



tatar-inform.ru

җавап бирер, ничек каршы торыр, дип күзәтә.

Олег Морозов сүзләренчә, Россиянең сәяси системасын какшату турында хыялланган көндәшләр, дустанә булмаган илләр моңа ирешә алмады.

– Аларның ике еллык тырышлыгы ни белән тәгәлләнгәнне күрсәтергә кирәк. Алар, иң элек, хакимияткә карата халык ышанычын киметергә теләде. Икенче бурыч – җәмгыятьне бүлү, илдә ыгы-зыгы тудыру, – дип аңлатты депутат. – Сайлауларның ничек тәмамланасын чамалыйм. Моны социологик тикшерүләр дә күрсәтә. Иң мөһиме бит нәтиҗә генә түгел. Иң мөһиме – Россиядә сайлау процедурасына, сәяси институтларга ышаныч барлыгын, авыр чакта лидер булырлык көчле кешене Президент итеп сайлавыбызны күрсәтү дә. Кеше, кемгә генә тавыш бирсә дә, сайлау нәтиҗәләренә ихтирам белән карарга тиеш.

Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе белгечләре Татарстанның барлык районнарын йөреп чыккан һәм тавыш бирүчеләрнең сорауларын туплаган.

– Мондый очрашуларның максаты – тавыш бирүчеләргә сайлау процессының хакимият белән халык арасында туры элемтә урнаштыру мөмкин икәнне күрсәтү, – диде федераль кунак.

Саклланганны саклар

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин сайлау вакытында фейк-хәбәрләр корбаны булмас өчен нишләргә кирәген аңлатты.

– Сүз дә юк, мәгълүмат куркынычсызлыгы мәсьәләсе соңгы елларда алгы сафка чыкты. Элемтәсез тормышны күз алдына да китереп булмый торган чорда яшибез. Мәгълүматны урлаганнар, дигән хәбәрләрне еш ишетеп торабыз, – диде министр. – Сайлаулар еш булып тора. Безнең сайлау участокларындагы элемтә системалары инде вакыт белән сыналган. Махсус киберштаб бар. Болар барысы да сайлау процессының куркынычсызлыгын тәэмин итә. Еш кына мәгълүматны тикшереп тә тормыйча тарату ягын карыйбыз. Моның нәтиҗәсе аяныч булырга мөмкин. Иң яхшысы – андый чакта телефонны читкә куеп тору да тирән итеп сулыш алу. Фейкларга килсәк, мәгълүматны каткат тикшерү һәм манипуляциягә бирешмәү мөһим. Ышанычлы мәгълүмат чараларына, күзәтүчеләр командасына мөрәҗәгать итегез. Сайлауга килеп, барысын да үз күзләрең белән күрүдән дә яхшысы юк.

КАЙЧАН? 15–17 март көннәре
КЕМНӘР? Кандидатлар дүртәү: Владимир Путин (үз-үзен тәкъдим итүче), Владислав Даванков («Новые люди»), Николай Харитонов (КПРФ), Леонид Слуцкий (ЛДПР)
КҮПМЕ? Республиканың Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматларына караганда, 2024 елның 1 гыйнварына Татарстанда 2928633 кеше тавыш бирү хокукына ия.

Фикер

Элла ПАМФИЛОВА, Россия Үзәк сайлау комиссиясе рәисе:
– Татарстандагы тавыш бирүчеләрнең битараф булмавы, активлыгы, кызыксынучанлыгы мине таң калдырды. Сайлау кампаниясенең мөһим этабына кереп барганда, шулай очрашу бик кирәк иде. Россия Президентын сайлау – мөһим сәяси вакыйга. Ул безнең илебезнең һәм кешеләрнең киләчәгенә йогынты ясаячак. Һәркем өстендә – зур җаваплылык. Безгә, оештыручыларга, иң мөһиме – сайлауны горурланырлык итеп оештыру. Ә халыкка барыбер булырга тиеш түгел. Тавыш бирүчеләрнең активлык кына күрсәтеп калмыйча, сайлау участокларына күзәтүче булып та баруын теләр идем. Бу безнең өчен дә бик мөһим.

(«Минем тавыш» онлайн форумы катнашучыларына видеомөрәҗәгатеннән)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында катнашучыларның Татарстан Республикасы территориясендә узара хезмәттәшлеге тәртибен Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында билгели (шул исәптән дәүләт юридик бюроларының әлеге түләүсез юридик ярдәм системаларында башка катнашучылар белән узара хезмәттәшлеге өлешендә);»;

3) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 1^{1} пункт өстәргә:

«1^{1}) Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил;»;

4) 10 статьяда:

а) исемендә «учреждениеләр,» сүзеннән соң «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә үз компетенциясе чикләрендә булыша.»;

5) 12 статьяда:

а) 1 өлешнең 3^{2} пунктында «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) инвалидларга медик-социаль экспертиза үткәрү, аларны реабилитацияләү һәм инвалидларны абилитацияләү;»;

6) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомстволыгындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт юридик бюросы» сүзләрен «әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 1^{1} өлеш өстәргә:

«1^{1}. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар юридик хокукый мәгълүмат җиткерүне һәм аны хокукый гыйлемле итүне Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.».

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунктчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 6-ТРЗ

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 4 өлештә «4^{1} өлешендә» сүзләрен «4^{1} һәм 4^{1-1} өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^{1-1} өлеш өстәргә:

«4^{1-1}. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрларын үзгәрүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгәндә анда үзе турындагы белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәсе әлеге күпфатирлы йорт региональ программага кертелгән календарь елдан соң килүче елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килә. Күпфатирлы йортның күрсәтелгән өлешендә урнашкан урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәсе барлыкка килгән датадан башлап капиталь ремонт өчен кертемне түләүдән азат ителә, әгәр дә күпфатирлы йортны эксплуатациягә тапшырылган датага кадәр мондый күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын булдыру алымын билгеләү турында карар кабул ителгән һәм гамәлгә ашырылган карар нигезендә, әгәр бу сроктан соң мондый күпфатирлы йортта урыннар милекчеләре тарафыннан башка карар кабул ителмәгән булса, түләнә.»;

в) 4^{2} өлештә «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «, яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат милкенә,» сүзләрен өстәргә;

2) 10 статьяның 10^{3} өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4^{1-1} өлеше нигезләмәләренең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программа расланганнан соң эксплуатациягә тапшырылган һәм әлеге күпфатирлы йортның параметрларын үзгәртүгә бәйле үзгәрешләр бу программага кертелгән һәм анда үзе турындагы белешмәләр чагылдырылган күпфатирлы йорт өлешендә урнашкан урыннар милекчеләре әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр күпфатирлы йортта капиталь ремонт өчен кертемнәр түләгән очракта, капиталь ремонт өчен кертемнәрнең артык саналган һәм күрсәтелгән урыннар милекчеләре тарафыннан түләнгән суммасы (урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәүгә бәйле рәвештә алар тарафыннан түләнгән пеняны да кертеп) автомат рәвештә аларның киләчәк чорга капиталь ремонт өчен кертемнәр түләү йөкләмәләрен үтәү исәбенә саналачак.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 7-ТРЗ

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Закон милкендә, хуҗалыгында яисә файдалануында музей әйберләре һәм музей туплаңмалары булган Татарстан Республикасында гамәлдә булган һәм яңадан төзелә торган барлык музейларга һәм башка оешмаларга, шулай ук физик затларга кагыла.»;

2) 9 статьяда:

а) 2 өлештә «башка оешмаларга» сүзләреннән соң «(дини оешмалардан да кертеп)» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) музей әйберләренә һәм музей туплаңмаларына бәйле исәпкә кую документларында музей әйберләре һәм музей туплаңмаларының булган әлеге музей әйберләренең һәм музей туплаңмаларының фактта булуын һәм физик саклануын, шулай ук мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының музей әйберләре һәм музей туплаңмаларына реставрация эшләрен үткәрү хокукына мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аттестация узган затлар тарафыннан мондый эшләр үткәрүне;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 8-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктта «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

б) 28 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук гомуми файдаланудагы су объектларыннан рекреация максатлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 11 пунктта «оештыру» сүзеннән соң «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле шәһәр округы территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

б) 36 пунктта «гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдалануның чикләүләре турында халыкка мәгълүмат бирү, гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп» сүзләрен «гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аларның яр буе полосаларыннан гражданнарның ирекле файдалана алуын тәэмин итүне дә кертеп, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү һәм мондый су объектларыннан файдалануның чикләүләре турында халыкка мәгълүмат бирү, шулай ук су объектларыннан рекреация максатлары өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 49^{1} статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан каралу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларын гамәлгә ашыруны килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.

Җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 – 5 пунктларында каралган халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан каралу нәтиҗәләре буенча килештерү турында мөрәҗәгать җибәрә.»;

б) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге статьяның 3 өлешендәге беренче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгате Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.

Әлеге статьяның 3 өлешендәге икенче абзацында каралган очракта халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыруны килештерү турында җирле үзидарә органының мөрәҗәгате Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау нәтиҗәләре халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыра башлауның күздә тотылган датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән җирле үзидарә органына җиткерелә.»;

4) 49^{2} статьяның 1 өлешендә «Җирле үзидарә органының халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турындагы килешү» сүзләреннән соң «(төп нөсхәсе)» сүзләрен өстәргә.

2 статья

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасыннан һәм 2 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы һәм 2 пунктының «а» пунктчасы 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 9-ТРЗ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6^{1} статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон белән хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Рәисе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы территориясендә сайлаулар билгеләү хакында тәкъдим җибәрергә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларга карата – тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 105 көн һәм кимендә 95 көн кала;

2) җирле үзидарә органнарына сайлауларга карата – тавыш бирү көненә кадәр иң күбе 95 көн һәм кимендә 85 көн кала.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 5^{1} һәм 5^{2} өлешләр өстәргә:

«5^{1}. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган төрле дәрәҗәдәге сайлауларда тавыш бирү көннәре берләштерелгән очракта, сайлауларны билгеләү хакындагы тәкъдим югарырак дәрәҗәдәге сайлаулар өчен билгеләнгән сроклар дәвамында җибәрелергә тиеш.

5^{2}. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган сайлаулар билгеләнгәннән соң Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, хәрби хәл кертелгән территория шушы сайлау округына керә торган булса, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә тиешле сайлаулар үткәрү хакында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 6 өлештә «әлеге статьяның 5 өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 5 яисә 5^{2} өлешендә каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча,» сүзләренә алмаштырырга;

г) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 6 өлешендә каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә каралган срокларны исәпкә алып, тиешле сайлауларны билгеләү хакында (шул исәптән сайлау гамәлләре срокларын кыскарту мөмкинлеге белән) яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аларны билгеләү турында тәкъдимен кире кагу хакында карар кабул итә, ә әлеге статьяның 5^{2} өлешендә каралган очракта хәрби хәл кертелгән Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә сайлаулар үткәрү турында йә сайлаулар үткәрүнең мөмкин булмавы хакында кичекмәстән карар кабул итә.»;

д) 8 өлештә «, әлеге статьяның 7 өлешендә һәм әлеге Кодексның 6 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 9 өлештә «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә сайлаулар билгеләнгәннән соң йә әлеге статьяның 5^{2} өлеше нигезендә аларны үткәрү хакында карар кабул ителгәннән соң сайлауларны әзерләү һәм үткәрү гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, тиешле сайлаулар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 11 өлештә «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «5 – 8 өлешләрендә» сүзләрен «5^{2} – 8 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 10 статьяның 4 өлешендә «закон» сүзен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

3) 16 статьяның 6 өлешендә «Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры шул комиссия катнаша торган» сүзләрен «Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры якындагы сайлауларны билгеләү өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 2, 3 һәм 7 пунктларында каралган срокларда шул комиссия катнаша торган» сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяда:

а) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 15 өлештә «4 – 7 һәм 10 өлешләрендә» сүзләрен «4 һәм 10 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 16 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына, әлеге өлешнең беренче абзацында каралган түләүләрдән тыш, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча сайлау комиссиясендә эшләгән өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 57 статьясындагы 3^{1} пункты нигезендә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән хезмәткә өстәмә түләү (бүләкләү) бирелергә мөмкин. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 57 статьясындагы 3^{1} пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән хезмәткә өстәмә түләүнең (бүләкләүнең) күләме һәм тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

6) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Хәрби частьларда төзелгән сайлау участокларындагы тавыш бирү урыннарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү бары тик әлеге Кодексның 23 статьясындагы 3 өлеше нигезендә аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителә.»;

7) 24 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

8) 33 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче – дүртенче абзацлар өстәргә:

«Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе иң күбе 15 вәкаләтле вәкил билгеләп куярга хокуклы.

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны уздырганда, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе иң күбе биш вәкаләтле вәкил билгеләп куярга хокуклы.

Кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкилләрнең гомуми санында сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен билгеләп куярга тиеш.»;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә каралган карар нигезендә теркәлергә тиеш. Сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләре сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан әлеге статьяның 2 – 4 өлешләрендә каралган карар һәм нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә һәм сайлау берләшмәсенең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле граждан паспортын яисә аны алыштыручы документын күрсәтеп теркәлергә тиеш. Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләрен теркәү әлеге статьяның 2 – 4 өлешләрендә күрсәтелгән документлар кергән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

в) 6 өлештә «туктатырга хокуклы» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә туктатырга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

9) 45 статьяның 6 өлешендәге икенче абзацында «Законда билгеләнгән срокта» сүзләрен «Әлеге Кодекста билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга, «законда билгеләнгән срокта» сүзләрен «әлеге Кодекста билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга;

10) 66 статьяда:

а) 4 өлештә «комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү» сүзләреннән соң «, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтү» сүзләрен өстәргә;

б) 12 өлештә «Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар, эшләр яисә хезмәтләр күрсәтү сатып алулар» сүзләреннән соң «, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алуларны да кертеп,» сүзләрен өстәргә, «тиешле сайлауларны оештыручы комиссия яисә аның карары нигезендә түбәндәге тиешле» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 13 өлештә «Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарларны, эшләрне яисә хезмәт күрсәтүләрне сатып алу» сүзләреннән соң «, федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алуны да кертеп,» сүзләрен өстәргә;

г) 14 өлештә «Сайлау кампаниясе уздыру чорында сайлау комиссияләренә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән һәм агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда булган Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары» сүзләрен «Агымдагы финанс елы ахырына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыяте филиалларында ачылган счетларда саклана торган сайлау кампаниясе уздыру чорында сайлау комиссияләренә тиешле дәрәҗәдәге сайлаулар әзерләүгә һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары, сайлау комиссияләренә федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары» сүзләренә алмаштырырга;

11) 67 статьяның 3 өлешендә «теләсә кайсы вакытта туктатырга мөмкин» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә теләсә кайсы вакытта туктатырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

12) 79 статьяда:

а) 6^{1} өлешнең алтынчы абзацында «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә инанырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлештә «, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, башкарылган санауның дөреслеген тикшереп, шуңа ышанырга хокуклы» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 80 статьяда:

а) 11 өлештә «сайлау комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия беркетмә төзегән әгъзаларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 13 өлештә «үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 14 өлештә «тиешле комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 15 өлештә «үзенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 83 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тиешле дәрәҗәдәге сайлауларны үткәргәндә, шул исәптән сайлаучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), сайлаучылар исемлекләрен төзегәндә, сайлаучылар тавышларын санаганда, тавыш бирү йомгакларын ясаганда һәм сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләгәндә закон нигезендә «Сайлаулар» ДАС (аның кайбер техник чаралары) файдаланылганда, тиешле сайлау комиссиясе «Сайлаулар» ДАСтан (аның кайбер техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә төркем төзи. Комиссиянең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр тавыш бирү йомгакларын ясауга, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә «Сайлаулар» ДАСка кертелә һәм аннан алына торган теләсә кайсы мәгълүмат белән танышырга хокуклы.»;

15) 91 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) сәяси партияләрнең ышанычлы затларын һәм вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән сәяси партияләрнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен терки, аларга билгеләнгән рәвештәге таныклыклар тапшыра;»;

16) 104 статьяның 2 өлешендә «тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләрен «якындагы тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләренә алмаштырырга, «бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган киләсе тавыш бирү көненә йә, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән тавыш бирү көненә кадәр башка көнгә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

17) 108 статьяның 1 өлешендәге 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) сайлау берләшмәләренең ышанычлы затларын һәм вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән сайлау берләшмәләренең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен терки, аларга билгеләнгән рәвештәге таныклыклар тапшыра;»;

18) 123 статьяның 2 өлешендә «тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләрен «якындагы тавыш бирү көненә билгеләнә алмаса» сүзләренә алмаштырырга, «бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш» сүзләрен «әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган киләсе тавыш бирү көненә йә, әлеге Кодексның 6 статьясындагы 4 – 7 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, күрсәтелгән тавыш бирү көненә кадәр башка көнгә билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15^{1} статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон белән хәрби хәл кертелгәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы референдумга чыгарыла торган мәсьәләнең әлеге Законның 9 статьясы таләпләренә туры килүен таныган көннән алып биш көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум билгеләү хакында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^{1} пункт өстәргә:

«4^{1}. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 4 пунктында каралган референдум билгеләнгәннән соң Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум уздыру турында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 5 пунктта «әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 4 яисә 4^{1} пунктларында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча,» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү турында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны билгеләү хакында тәкъдимен кире кагу турында карар кабул итә, ә әлеге статьяның 4^{1} пунктында каралган очракта хәрби хәл кертелгән Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә референдум уздыру хакында йә референдум уздыруның мөмкин булмавы турында кичекмәстән карар кабул итә.»;

д) 7 пунктта «, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктта «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң йә әлеге статьяның 4^{1} пункты нигезендә аны уздыру турында карар кабул ителгәннән соң референдумны әзерләү һәм уздыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдум Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 10 пунктта «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «4 – 7 пунктларында» сүзләрен «4^{1} – 7 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. **Референдум комиссиясен тарату**

Референдум комиссиясе Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә таратылырга мөмкин.»;

3) 22 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Хәрби частьларда төзелгән референдум участокларындагы тавыш бирү урыннарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү бары тик әлеге статьяның 11^2 пункты нигезендә аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителә.»;

4) 58 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум уздырганда, шул исәптән референдумда катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), референдумда катнашучылар исемлекләрен төзегәндә, референдумда катнашучылар тавышларын санаганда, тавыш бирү йомгакларын ясаганда һәм референдум нәтиҗәләрен билгеләгәндә закон нигезендә «Сайлаулар» ДАС (аның кайбер техник чаралары) файдаланылганда, тиешле референдум комиссиясе «Сайлаулар» ДАСтан (аның кайбер техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен Федераль законда каралган тәртиптә төркем төзи. Референдум комиссиясенең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр тавыш бирү йомгакларын ясауга, референдум нәтиҗәләрен билгеләүгә бәйле рәвештә «Сайлаулар» ДАСка кертелә һәм аннан алына торган теләсә кайсы мәгълүмат белән танышырга хокуклы.».

3 статья

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18^1 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, «Хәрби хәл турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон белән хәрби хәл кертелгәндә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы референдумга чыгарыла торган мәсьәләнең әлеге Законның 10 статьясы таләпләренә туры килүен таныган көннән алып биш көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисе Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум билгеләү хакында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 4^1 пункт өстәргә:

«4^1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 4 пунктында каралган референдум билгеләнгәннән соң Татарстан Республикасы территориясендә, Татарстан Республикасы территориясенең бер өлешендә хәрби хәл кертелгән очракта, хәрби хәл кертелгән территория шушы референдум округына керә торган булса, Татарстан Республикасы Рәисе хәрби хәл кертелгән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенә референдум уздыру хакында тәкъдим җибәрергә хокуклы.»;

в) 5 пунктта «әлеге статьяның 4 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «әлеге статьяның 4 яисә 41 пунктында каралган тәкъдим кергән көннән алып биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәрге көннән дә соңга калмыйча,» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 5 пунктында каралган консультацияләр нәтиҗәсе буенча Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе референдум билгеләү хакында яисә Татарстан Республикасы Рәисенең аны билгеләү турында тәкъдимен кире кагу хакында карар кабул итә, ә әлеге статьяның 4^1 пунктында каралган очракта хәрби хәл кертелгән территориядә референдум уздыру турында йә референдум уздыруның мөмкин булмавы хакында кичекмәстән карар кабул итә.»;

д) 7 пунктта «, әлеге статьяның 6 пунктында билгеләнгән срокларны истә тотып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 8 пунктта «үткәрү турындагы» сүзләрен «билгеләү (үткәрү) турындагы» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә, әлеге статьяның 7 пункты нигезендә референдум билгеләнгәннән соң йә әлеге статьяның 4^1 пункты нигезендә аны уздыру хакында карар кабул ителгәннән соң референдумны әзерләү һәм уздыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, референдум Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары белән кичектерелә, ул бу хакта кичекмәстән Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.»;

з) 10 пунктта «кичектереп тору» сүзләреннән соң «(туктатып тору)» сүзләрен өстәргә, «4 – 7 пунктларында» сүзләрен «4^1 – 7 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 24 статьяга түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:

«15. Хәрби частьларда төзелгән референдум участокларындагы тавыш бирү урыннарында фотога һәм (яисә) видеога төшерү бары тик әлеге статьяның 11^2 пункты нигезендә аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре тарафыннан һәм тиешле хәрби часть командиры белән килештереп кенә рөхсәт ителә.».

4 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 10-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2024 елның 15 февралендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) әлеге Законның 17^3 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдәге (алга таба – анкетадагы белешмәләр) аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле карары белән үзгәргән белешмәләрдән тыш, яллаучы вәкиленә язмача хәбәр итәргә.»;

2) 17 статьяның 3 өлешендә «дәүләт хезмәткәре тарафыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 17^3 статья өстәргә:

«17^3 статья. **Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү**

1. Граждан дәүләт хезмәтенә урнашканда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнгән рәвештәге анкета тапшыра.

2. Дәүләт хезмәткәре анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә язмача хәбәр итә.

3. Анкетадагы белешмәләр яллаучы вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга язмача соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, әлеге Законның 41^1 статьясында каралганнарын да кертеп, җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратыла торган мәгълүматны әлеге соратуны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

4) 31 статьяның 1 өлешендәге 6^1 пунктында «Кораллы Көчләренә» сүзләреннән соң «яисә Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренә» сүзләрен өстәргә;

5) 32 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 пунктлар өстәргә:

«12) 2014 елның 11 маеннан 2022 елның 23 февраленә кадәр Россия Федерациясе гражданлыгы алган һәм шушы чорда, даими яшәү срогына бәйсез рәвештә, Донецк Халык Республикасы яисә Луганск Халык Республикасы территориясендә даими яшәгән Россия Федерациясе гражданнары һәм элек Украина гражданлыгында булган һәм 2022 елның 24 февраленнән башлап Россия Федерациясе гражданлыгы алган Россия Федерациясе гражданнары Украина ССР Конституциясе, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар нигезендә төзелгән дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында 1992 елның 1 гыйнварыннан 1993 елның 31 декабренә кадәр биләгән җитәкчеләр, белгечләр вазыйфаларын, шулай ук сайлаулы вазыйфаларны;

13) әлеге өлешнең 12 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары 1994 елның 1 гыйнварыннан дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны биләү, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә яисә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә урнашу көненә кадәр Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә биләгән вазыйфаларны (Россия Федерациясе законнары нигезендә террорчы булып танылган хәрби формированиеләрдә һәм башка формированиеләрдә хезмәт итү чорларыннан, Россия Федерациясе законнары нигезендә экстремист булып танылган оешмаларда ихтыярый әгъза булып тору чорларыннан, Донецк Халык Республикасына, Луганск Халык Республикасына һәм аларның халкына каршы хокукка каршы гамәлләрдә катнашу чорларыннан, Украина кораллы көчләре һәм башка формированиеләре составында Россия Федерациясенә каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашу чорларыннан тыш), шул исәптән:

а) депутат вазыйфаларын;

б) дәүләт хезмәткәрләре чиннары (ранглары) бирелгән вазыйфаларны;

в) судьялар вазыйфаларын;

г) дипломатик ранглар бирелгән вазыйфаларны;

д) прокуратура хезмәткәрләренең класслы чиннары бирелгән вазыйфаларны;

е) хәрби званиеләр һәм махсус званиеләр бирелгән вазыйфаларны;

ж) чиннар (ранглар) бирелгән җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны;

з) Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы дәүләт вазыйфаларын;

и) Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе хәрби-граждан администрацияләре вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы вазыйфаларны;

к) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә эшләгән гавами хакимият органнары вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы башка вазыйфаларны.»;

6) 34 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «конкурс нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 38 статьяның 1 өлешендә «дәүләт хезмәткәрләреннән (гражданнардан)» сүзләрен «дәүләт хезмәткәрләреннән, гражданнардан» сүзләренә алмаштырырга;

8) 39 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясенең персональ белешмәләр өлкәсендәге законнарында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәткәренең бары тик автоматлаштырылган эшкәртү нәтиҗәсендә генә алынган персональ белешмәләре нигезендә дәүләт хезмәткәренә карата юридик нәтиҗәләр барлыкка китерә яисә аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә башка рәвештә кагыла торган карарлар кабул итү тыела;»;

9) 41 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктта «дәүләт хезмәткәрләрен» сүзләреннән соң «, гражданнарны» сүзен өстәргә;

б) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) дәүләт хезмәтенә урнашканда граждан тарафыннан һәм дәүләт хезмәткәре аны узу чорында аның тарафыннан бирелә торган белешмәләрне тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле 16^1 пункт өстәргә:

«16^1) дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр белән эшләүгә билгеләнгән рәвештәге рөхсәтне рәсмиләштерү;».

2 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) әлеге Кодексның 18^2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрдәге (алга таба – анкетадагы белешмәләр) аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары белән үзгәргән белешмәләрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә.»;

2) 15 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә урнашканда һәм (яисә) аны узу чорында чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы ялган документлар һәм (яисә) белә торып ялган белешмәләр тапшырса йә чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачау итә торган мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәүне дәлилли торган документлар һәм (яисә) белешмәләр тапшырмаса;»;

3) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 18^2 статья өстәргә:

«18^2 статья. **Анкета тапшыру, анкетада булган белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү**

1. Граждан муниципаль хезмәткә урнашканда анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр анкетада булган белешмәләрдәге аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итә.

3. Анкетаның рәвеше, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) яисә ул вәкаләт биргән затның карары белән тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга язмача соратулар, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия булган гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратыла торган мәгълүматны әлеге соратуны алган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

4) 19 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Кодексның 18^2 статьясында каралган анкетаны;»;

б) 4 өлештә «белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

5) 29 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11^1 һәм 11^2 пунктлар өстәргә:

«11^1) 2014 елның 11 маеннан 2022 елның 23 февраленә кадәр Россия Федерациясе гражданлыгы алган һәм шушы чорда, даими яшәү срогына бәйсез рәвештә, Донецк Халык Республикасы яисә Луганск Халык Республикасы территориясендә даими яшәгән Россия Федерациясе гражданнары һәм элек Украина гражданлыгында булган һәм 2022 елның 24 февраленнән башлап Россия Федерациясе гражданлыгы алган Россия Федерациясе гражданнары Украина ССР Конституциясе, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә гамәлдә булган норматив хокукый актлар нигезендә төзелгән дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында 1992 елның 1 гыйнварыннан 1993 елның 31 декабренә кадәр биләгән җитәкчеләр, белгечләр вазыйфаларында, шулай ук сайланулы вазыйфаларда;

11^2) әлеге өлешнең 11^1 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнары 1994 елның 1 гыйнварыннан дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны биләү, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә яисә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә урнашу көненә кадәр Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә биләгән вазыйфаларда (Россия Федерациясе законнары нигезендә террорчы булып танылган хәрби формированиеләрдә һәм башка формированиеләрдә хезмәт итү чорларыннан, Россия Федерациясе законнары нигезендә экстремист булып танылган оешмаларда ихтыярый әгъза булып тору чорларыннан, Донецк Халык Республикасына, Луганск Халык Республикасына һәм аларның халкына каршы хокукка каршы гамәлләрдә катнашу чорларыннан, Украина кораллы көчләре һәм башка формированиеләре составында Россия Федерациясенә каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашу чорларыннан тыш), шул исәптән:

а) депутат вазыйфаларында;

б) дәүләт хезмәткәрләре чиннары (ранглары) бирелгән вазыйфаларда;

в) судьялар вазыйфаларында;

г) дипломатик ранглар бирелгән вазыйфаларда;

д) прокуратура хезмәткәрләренең класслы чиннары бирелгән вазыйфаларда;

е) хәрби званиеләр һәм махсус званиеләр бирелгән вазыйфаларда;

ж) чиннар (ранглар) бирелгән җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларда;

з) Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы дәүләт вазыйфаларында;

и) Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе хәрби-граждан администрацияләре вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы вазыйфаларда;

к) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы законнары, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе норматив хокукый актлары яисә Украина законнары нигезендә эшләгән гавами хакимият органнары вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү максатларында кертелгән шушы органнардагы башка вазыйфаларда;»;

6) 34 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә урнашканда граждан тарафыннан һәм муниципаль хезмәткәр аны узу чорында аның тарафыннан бирелә торган белешмәләрне тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11^1 пункт өстәргә:

«11^1) дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр белән эшләүгә билгеләнгән рәвештәге рөхсәтне рәсмиләштерү;».

3 статья

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 3, 8 пунктлары, 9 пунктының «б» һәм «в» пунктчалары һәм 2 статьясындагы 1 – 4 һәм 6 пунктлары 2024 елның 12 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2024 ел, 01 март. № 11-ТРЗ

КОМПЛЕКСЛЫ КАДАСТР ЭШЛӘРЕН БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

2024 елның 26 февраленнән 2024 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан түбәндәге күчемсез милек объектларына карата:

– Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге 16:16:081901, 16:16:081101, 16:16:083101); Красна авыл җирлеге 16:16:081501, 16:16:081401; Семиозерка авыл җирлеге 16:16:212801, 16:16:213001, 16:16:211301, 16:16:211401, 16:16:211601, 16:16:212601; Усад авыл җирлеге 16:16:171701; Чыпчык авыл җирлеге 16:16:181302, 16:16:181601; Дачное авыл җирлеге 16:16:213201;

– Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге 16:24:010101;

– Питрәч муниципаль районы Богородское авыл җирлеге 16:33:021139, 16:33:021145, 16:33:021141, 16:33:021142; Колай авыл җирлеге 16:33:051607; Белкино авыл җирлеге с/п 16:33:010101; Кощаково авыл җирлеге 16:33:080201, 16:33:180520, 16:33:080302; Ленино-Кокушкино авыл җирлеге 16:33:100103; Шәле авыл җирлеге 16:33:170420; Питрәч авыл җирлеге 16:33:120105; Шигали авыл җирлеге 16:33:180201, 16:33:181623, 16:33:181625, 16:33:180801;

– Тукай муниципаль районы, Мәләкәс авыл җирлеге 16:39:010901; Князево авыл җирлеге 16:39:031101; Бәтке авыл җирлеге 16:39:040601; Борды авыл җирлеге 16:39:050501; Түбән Суыксу авыл җирлеге 16:39:070401;

– Әлмәт муниципаль районы Әлмәт ш. 16:45:040129;

– Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге 16:30:010304, 16:30:010310, 16:30:010312, 16:30:010314; Түбән Кама ш. 16:30:010501; Каенлы авыл җирлеге 16:30:020301, 16:30:020402; Сухарево авыл җирлеге 16:30:080101; Майская Горка авыл җирлеге 16:30:100301;

– Казан ш. Авиатөзелеш районы 16:50:220210;

– Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге 16:27:070201;

– Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге 16:34:050101; Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге 16:34:160201; Юлсубино авыл җирлеге 16:34:270101;

– Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге 16:35:010101; Олы Кибәче авыл җирлеге 16:35:020101; Олы Шыңар авыл җирлеге 16:35:040101, 16:35:040201;

– Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлеге 16:39:031001; Мусабай-Завод авыл җирлеге 16:39:080601; Кече Шилнә авыл җирлеге 16:39:101501; Шилнәбаш авыл җирлеге 16:39:120501, 16:39:120601, 16:39:031301; Күзкәй авыл җирлеге 16:39:180901;

– Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге с/п 16:42:200302;

– Чаллы ш. 16:52:010205, 16:52:010306, 16:52:010308,

26.02.2024 № 924000008-ОК, дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарылачак. Заказчы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы. Почта адресы: Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 26 й., телефон: 8 (843) 221-40-60.

1. Комплекслы кадастр эшләрен кадастр инженеры башкара:

ФИО: Вәлиева Альбина Рафаил кызы; адресы: 420014, ТР, Зеленодольск ш., Ленин ур., 44 й., 102 оф.

Почта: filial@16.kadastr.ru; телефон: (843) 514-90-77 (2224).

Идентификация номеры 16-11-266, 05.03.2011.

«АКИ Поволжье» үзкөйләнешле оешма ассоциациясе әгъзасы булып тора, реестрда 1669.

Дәүләт контракты төзелгән, кадастр инженеры түбәндәге оешманың хезмәткәре булып тора: «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең ТР буенча филиалы.

ФИО: Нигъмәтуллина Мария Сергеевна; адресы: 420054, ТР, Казан ш., Владимир Кулагин ур., 1 й.;

Почта: nigmatullinams@16.kadastr.ru; телефон: (843) 514-90-77 (2546).

Идентификация номеры 16-14-686, 03.04.2014.

«АКИ Поволжье» үзкөйләнешле оешма ассоциациясе әгъзасы булып тора, реестрда – 0350.

Дәүләт контракты төзелгән, кадастр инженеры түбәндәге оешманың хезмәткәре булып тора: «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең ТР буенча филиалы.

2. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 4 өлеше нигезендә элек исәпкә алынган булып саналган яки үзләре турында мәгълүматлар «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, ЕГРНда, элек исәпкә алынган буларак, мондый күчемсез милек объектлары турында мәгълүматлар булмаган очракта, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына (алга таба – ЕГРН) кертеп булырдай күчемсез милек объектлары хуҗалары комплекслы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына – комплекслы кадастр эшләрен башкаручыга мондый күчемсез милек объектларына карата материаллар һәм документларны, шулай ук «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законның 21 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә расланган, әлеге күчемсез милек объектларына хокукны билгеләүче яки раслаучы документлар күчермәләрен тапшыруга хокуклы.

3. Күчемсез милек объектлары – җир кишәрлекләре, биналар, корылмалар, тәмамланмаган төзелеш объектлары хуҗалары, комплекслы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә басылып чыкканнан соң утыз эш көне эчендә, комплекслы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына – комплекслы кадастр эшләрен башкаручыга комплекслы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән, күчемсез объектка хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук үзенең файдасына күчемсез милек объектына хокукны чикләү теркәлгән зат белән элемтәгә керү өчен электрон почта адресы һәм (яки) почта адресы (алга таба – милек хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы) буенча, милек хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы турында мәгълүматларны ЕГРНга кертү һәм алга таба мондый затларга комплекслы кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча территориянең карта-планы проектын әзерләүне төгәлләү һәм җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясен үткәрү турында мәгълүматлар тапшыруга хокуклы.

4. Комплекслы кадастр эшләре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектлары хуҗалары комплекслы кадастр эшләрен башкаруга комачауламаска һәм комплекслы кадастр эшләрен башкаручыны графикта билгеләнгән вакытта күрсәтелгән күчемсез милек объектларына үткәреп җибәрүгә бурычлы.

5. Комплекслы кадастр эшләрен башкару графигы

Комплекслы кадастр эшләрен башкару урыны	Комплекслы кадастр эшләрен башкару вакыты
– Биектау муниципаль районы (Биектау авыл җирлеге 16:16:081901, 16:16:081101, 16:16:083101; Красна авыл җирлеге 16:16:081501, 16:16:081401; Семиозерка авыл җирлеге 16:16:212801, 16:16:213001, 16:16:211301, 16:16:211401, 16:16:211601, 16:16:212601; Усад авыл җирлеге 16:16:171701; Чыпчык авыл җирлеге 16:16:181302, 16:16:181601; Дачное авыл җирлеге 16:16:213201); – Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге 16:24:010101; – Питрәч муниципаль районы (Богородское авыл җирлеге 16:33:021139, 16:33:021145, 16:33:021141, 16:33:021142; Колай авыл җирлеге 16:33:051607; Белкино авыл җирлеге 16:33:010101; Кощаково авыл җирлеге 16:33:080201, 16:33:180520, 16:33:080302; Ленино-Кокушкино авыл җирлеге 16:33:100103; Шәле авыл җирлеге 16:33:170420; Питрәч авыл җирлеге 16:33:120105; Шигали авыл җирлеге 16:33:180201, 16:33:181623, 16:33:181625, 16:33:180801); – Тукай муниципаль районы (Мәләкәс авыл җирлеге 16:39:010901; Князево авыл җирлеге 16:39:031101; Бәтке авыл җирлеге 16:39:040601; Борды авыл җирлеге 16:39:050501; Түбән Суыксу авыл җирлеге 16:39:070401); – Әлмәт муниципаль районы Әлмәт ш. 16:45:040129; – Түбән Кама муниципаль районы (Афанас авыл җирлеге 16:30:010304, 16:30:010310, 16:30:010312, 16:30:010314; Түбән Кама ш. 16:30:010501; Каенлы авыл җирлеге 16:30:020301, 16:30:020402); Сухарево авыл җирлеге 16:30:080101; Майская Горка авыл җирлеге 16:30:100301); – Казан ш. Авиатөзелеш районы 16:50:220210; – Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге 16:27:070201; – Балык Бистәсе муниципаль районы (Олы Елга авыл җирлеге 16:34:050101; Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге 16:34:160201; Юлсубино авыл җирлеге 16:34:270101); – Саба муниципаль районы (Арташ авыл җирлеге 16:35:010101; Олы Кибәче авыл җирлеге 16:35:020101; Олы Шыңар авыл җирлеге 16:35:040101, 16:35:040201); – Тукай муниципаль районы (Князево авыл җирлеге 16:39:031001; Мусабай-Завод авыл җирлеге 16:39:080601; Кече Шилнә авыл җирлеге 16:39:101501; Шилнәбаш авыл җирлеге 16:39:120501, 16:39:120601, 16:39:031301; Күзкәй авыл җирлеге 16:39:180901); – Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге 16:42:200302; – Чаллы ш. 16:52:010205, 16:52:010306, 16:52:010308	26.02.2024 – 01.12.2024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЛАРЫ

«Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында

2024 елда «Сабан туе» татар халык бәйрәмен үткәрү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге срокларда уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә) – 2024 елның 8–9 июнендә;

Чаллы шәһәрендә – 2024 елның 15 июнендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2024 елның 23 июнендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән срокларда уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән срокларда оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 05 март
№ 173

«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

2024 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2024 елның 26 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 05 март
№ 174

«НИГЕЗ – АВЫЛДА, АВЫЛНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ – ЭШМӘКӘРДӘ»

tatarstan.ru

<Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гомумән, чыгышларда хәрби операциядә катнашучы егетләр, аларга күрсәтелгән ярдәм чаралары турында күп әйтелде. Моннан тыш, читтә яшәүче милләттәшләребезнең карашы Казанга төбәлгәнлеге дә кат-кат ассызыкланды. Әйтик, Фаил Бердиев узган ел Әстерханда узган Бөтенроссия авыл Сабан туе уңаеннан Рәискә мөрәҗәгать итеп, болай әйтте: «Сезнең ярдәм булмаса, шундый зур бәйрәмнәр оештыра алмас идек. Татарстан безне ярдәмсез калдырмый. Олыларны да, яшьләрне дә онытмыйсыз. Башка милли иҗтимагый оешмалар безгә ак көнләшү белән карый. «Татарстан булу – зур бәхетегез», – диләр».

Эшләрен әти-әнисе белән бергәләп алып баручы Удмуртия эшмәкәре Эльвира Хәлимова да, «Күршеләре бай булса, тавыклары тук була» дигән гыйбарәне кулланып, бар халыкның кәефен күтәреп алды. Соңыннан ул «ВТ» хәбәрчесенә әлеге ярдәмне каян көтүләре турында да сөйләде.

– Без «Яратып» дигән бренд астында казылыклар, колбасалар, ярымфабрикатлар эшлибез. Әнисе үз баласына ризыкларны ничек итеп яратып әзерли, без дә үз сатып алучыларыбызны шулай кадерлибез. Үзебез дә мөселман гаиләсе булгач, сыйфатлы, чиста, хәләл продукция генә җитештерергә тырышабыз. «Хәләл» юнәлеше буенча эшләгәндә Татарстанга өметебез зур. Алар безгә сертификат алуда ярдәм кулы суздылар, аңлаттылар, күрсәттеләр. Моның өчен без аларга бик рәхмәтле. Киләчәктә дә алардан өйрәнәсе эшләребез байтак әле, – диде эшмәкәр ханым.

Башкортстан фермеры Дамир Гыйльманов исә авылны саклау өчен ил күләмендә күпьеллык программалар кабул итәргә кирәклеген әйтте.

– Монда җыелган бар кешене дә бер мәсьәлә – авылларның язмышы борчый. Авыл – илне туендыручы, азык белән тәэмин итүче. Аны саклау ул – милләтне саклау. Әгәр яшьләрнең үз хуҗалыгы, эше яшәү чыганагы була алмый икән, алар, әлбәттә, авылдан китү ягын карый. Авылда яшәү шартларын гына көйләү җитми, ә эш урыннары булдырырга, яшәү өчен йортлар, балалар укытыр өчен мәктәпләр кирәк. Авылны саклап калу һәм үстерү өчен, ил күләмендә күпьеллык программалар кабул итәргә кирәк, – диде.

Җыен кунакларын Рөстәм Миңнеханов сәламләде һәм татарлыкны саклаганга рәхмәтен белдерде.

– Безнең нигез – авылда, авылның эчтәлеге – эшмәкәрдә, – диде ул. – Монда килгән кешеләр арасында хөкүмәт хисабына эшләүче юк, барыгыз да эшли, башкаларга эш бирә. Күргәзмәне карасак, бер җирдә дә шундый тәмле ризыкларны пешерә алмыйлар. Сез татарлыкны югалтмыйсыз, әле безгә читтә торган татарлардан өйрәнергә кирәк. Татар конгрессы сезгә таянып эшли. Безнең киләчәк – сезнең кебек кешеләрдә, һәммәгезгә рәхмәт.

Татарстанда узачак халыкара чараларда халыкның көчен, куәтен күрсәтергә кирәклеген әйтте ул. Ә алда үзебезне, Казанны күрсәтер өчен форсатлар шактый күп.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Белдерү

Кадастровым инженером Ирбулатовым Маратом Рафиковичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-я Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600488084, электронная почта marat_327@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-15-841) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:171747:29, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Рощинская, д. 107/90, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Миронов Валерий Викторович, почтовый адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Авангардная, д. 151, кв. 8.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10:00 до 18:00 часов по адресу: 420100, г. Казань, ул. 2-я Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1, 08.04. 2024 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, 2-я Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:50:171747:14; 16:50:171747:30; 16:50:171747 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

ЗАКОННАР ҮЗ КӨЧЕНӘ КЕРДЕ

Яңалык

Дәүләт Советының илле беренче утырышында кабул ителгән республика законнары үз көченә керә. Үзгәрешләр, түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән, дәүләт һәм муниципаль хезмәткә кабул итүдән алып, фатирларны капиталь ремонтлауга взнослар түләүгә кадәр, тормышыбызның төрле өлкәләренә кагыла. Законнардагы яңалыклар турында тулырак аңлатып үтәбез.

Ятим балаларга торак сатып алуга акча бирелә

27 февральдә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына, «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Закон үз көченә керде.

Закон ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга өстәмә ярдәм чараларын билгели. Аерым алганда, аларга төзекләндерелгән торак юнәтү яки ипотека кредитын тулысынча каплау өчен сертификатлар алу мөмкинлеге бирелә. Шул ук вакытта торак фондыннан түләү алыргамы яки әзер фатирмы икәнен алар үзләре хәл итәчәк.

Түләү бер тапкыр бирелә. Аны алучы алга таба махсус торак фондыннан фатирга дәгъва итә алмый. Түләү алу хокукына минималь хезмәт хакыннан ким булмаган керемгә ия булучы, салымнарны вакытында түләп баручы, психик чирдән, хәмергә яки наркотикларга бәйлелектән интекмәүче, хөкем ителмәгән 23 яшькә җитүче ятимнәр ия.

Түләүдән файдаланып сатып алына торган торак мәйданы 33 кв. метрдан ким булмаска тиеш. Минималь түләү күләме Татарстандагы торакның уртача базар бәясеннән чыгып исәпләнә. Хәзер фатир сатып алу өчен түләү күләме якынча 4,4 млн сум тәшкил итәргә тиеш.

Бушлай юридик ярдәм алу җиңеләя

1 мартта (2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 5 пунктындагы «б» пунктчасыннан тыш) «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 6-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Закон Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне, шулай ук ил төбәкләрендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрне түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдә катнашучылар исәбенә кертә. Дәүләт юридик бюролары һәм адвокатлары тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтелергә тиешле очраклар исемлеге дә киңәйтелә. Аерым алганда, бу исемлеккә инвалидларны абилитацияләү мәсьәләләре буенча бушлай консультацияләр үткәрү кертелгән.

Закон шулай ук Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне дә күздә тота.

Сулардан файдалануга күз-колак

1 мартта (1 статьяның 1 пунктындагы «а» пунктчасыннан һәм 2 пунктындагы «а» пунктчасыннан тыш – алар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 9-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Муниципаль районнар һәм шәһәр округларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә сулардан ял итү максатында файдалану кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук планлаштырылган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү мәсьәләсе кертелгән.

Шулай ук әлеге законда чит дәүләтләрнең дәүләти-территориаль, административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләре вәкилләре белән очрашулар, консультацияләр һәм башка чаралар рәвешендә, җирле үзидарә органнарының халыкара, тышкы икътисадый бәйләнешләрне гамәлгә ашыруын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерү вакытын киметү каралган.

Сайлау комиссиясендә эшләгән өчен түләргә мөмкиннәр

12 мартта «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 10-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керә.

Законда хәрби хәл кертелгән очракта сайлаулар һәм референдумнар үткәрү тәртибе тәгаенләнә һәм участок комиссияләрен формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертелә.

Моннан тыш, законда сайлауга әзерләнгәндә һәм аны уздырганда хәлиткеч тавыш хокукына ия булган сайлау комиссиясе әгъзасы хезмәтенә өстәмә түләү күздә тотылган. Аерым алганда, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә өстәмә түләү мөмкинлеге каралган.

Территорияләрне комплекслы үстерү

27 февральдә «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 21 статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 5-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Законда республика Министрлар Кабинетына территорияне комплекслы үстерү операторын билгеләү, шулай ук мондый оператор белән территорияне комплекслы үстерү турында карарны гамәлгә ашыру максатында төбәк башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы белән килешү төзү тәртибен билгеләү буенча вәкаләтләр бирелгән.

Законда шулай ук территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыручы юридик затның милкенә мондый территория чикләренә кертелгән күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрне тапшыру мөмкинлеге каралган.

Капиталь төзекләндерү өчен түләү күпфатирлы йортны файдалануга тапшырганнан соң 6 ай эчендә исәпләнәчәк

1 мартта «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Закон файдалануга этаплап тапшырыла торган күпфатирлы йортта (шул исәптән аерым секцияләре) милекчеләрнең гомуми мөлкәткә капиталь төзекләндерү өчен кертемнәр түли башлау кагыйдәсен билгели.

Закон нигезендә, капиталь төзекләндерүнең төбәк программасы расланганнан соң һәм, күпфатирлы йортның параметрлары үзгәртелгән очракта, аның турында мәгълүматлар программада чагылдырылганнан соң файдалануга тапшырылган күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренә капиталь төзекләндерү буенча взнос түләү бурычы, рәсми басылып чыкканнан соң алты ай узгач барлыкка килә.

Волонтерлык оешмаларына игътибар арта

26 февральдә «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Республика законнарын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән законда дәүләт хакимияте органнары тарафыннан волонтерлык эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чараларының мөмкин булган формалары һәм ярдәм итү юллары билгеләнә.

Хакимият һәм җирле үзидарә органнарына шулай ук ихтыярыйлык (волонтерлык) буенча ресурс үзәкләренә ярдәм итү, шул исәптән финанс, матди һәм кадрлар белән тәэмин итүне кертеп, вәкаләтләре билгеләнә.

Музейдагы байлыкның сакланылышы тикшерелә

1 мартта «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 8-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Закон, музей тупланмаларының сакланылышын һәм бөтенлеген тәэмин итү максатыннан, музей әйберләренең һәм музей коллекцияләренең чынлыкта булу-булмавын һәм физик сакланылышын тикшерүне күздә тота. Шул ук вакытта музей әйберләрен һәм музей коллекцияләрен туплауны, исәпкә алуны, саклауны һәм куллануны оештыруның бердәм кагыйдәләре Россия Мәдәният министрлыгы тарафыннан раслана.

Закон шулай ук дәүләт милке булган музей әйберләрен һәм музей тупланмаларын оешмаларга түләүсез файдалануга тапшыру мөмкинлегеген күздә тота. Бу эш, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тиешле килешүләр нигезендә, Россия Мәдәният министрлыгы рөхсәте белән башкарыла.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен анкетаның бердәм формасы кертелә

1 мартта (2024 елның 12 мартыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 9 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларыннан һәм 1, 3, 8 пунктларыннан, 2 статьясының 1–4 һәм 6 пунктларыннан тыш) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 11-ТРЗ номерлы Закон үз көченә керде.

Закон буенча дәүләт яки муниципаль хезмәткә кабул ителгәндә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган анкетаның бердәм формасы билгеләнә. Анкетаның формасы, шул исәптән андагы мәгълүматлар исемлеге, шулай ук аларны үзгәртү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты акты белән билгеләнәчәк.

Шулай ук, закон нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр анкетада үзләренә мәгълүм булган үзгәрешләр турында эшкә яллаучы вәкиленә язмача рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

Кино

Бер гасыр

«ТАТАРКИНО» (ЯКИ ТАТАР КИНОСЫ) 100 ЯШЬЛЕГЕН НИЧЕК КАРШЫЛАР?

Бездә кино өлкәсе һәрвакыт диярлек бәхәс тудырды. Хәтта Татарстан кинематографиясенең 100 еллыгына багышланган матбугат очрашуы да бәхәссез узмады. Без әле кая барабыз? Ә кая барырга тиеш? Татар киносына күпме акча кирәк?

Татарстан өчен генә түгел, бөтен Россия өчен мөһим вакыйга. Татар киносының 100 еллыгына Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әнә шундый бәя бирде.

– 1924 елның 13 февралендә «Таткино» татар кинематография бүлеге оеша. Шушы көннән татар киносының елъязмасы языла башлый, – диде Дамир Натфуллин. – Соңгы елларны Татарстан киносы өчен үсеш еллары буларак тасвирларга була. Бу җәһәттән мисал итеп Казан мөселман кинофестивален китерергә була. Соңгы елларда без федераль прокат белән дә якыннан таныштык. Болар барысы да татар киносын зур киләчәк көтүен раслый.

«Татаркино» оешмасы директоры Миләүшә Айтуганова 100 еллык уңаеннан үткәреләчәк чаралар турында сөйләде. Әйтик, 12 мартта Татарстан Мәдәният министрлыгы уздырган конкурста катнашучыларның кинопроектларын тәкъдим итү булачак. Сүз уңаеннан, министрлык 10 кинопроектка 8 млн сум акча бүлеп куйган. Бу суммага әйләнеп кайтырбыз әле. 13 мартта исә башка илләр белән хезмәттәшлеккә багышланган «түгәрәк өстәл», ә кичен Филармониядә тантаналы чара узачак.

Шулай да, без татар киносының 100 еллыгын билгеләп үтәбезме, әллә «Татаркино» оешмасыныкынмы? Матбугат очрашуында Россия Кинематографистлар берлегенең Татарстан бүлеге рәисе Илдар Ягъфәров көтелмәгәнрәк сорау бирде. Югыйсә дата инде узып киткән, 100 еллык уңаеннан чаралар әзерләнә…

– Кинематографистлар берлеге әгъзасы буларак, минем өчен мөһим сорау бу. Татарстан киносы турында сөйләгәндә, ни өчен Казан кинохроника студиясе турында берни дә әйтелми? Мине дөрес аңлавыгызны үтенәм, мин кинематографистларны якларга тиеш, – диде ул.

Миләүшә Айтуганова тарихның бу битләренә 100 еллыкка чыгарылган китапта һәм «100 ел – 100 мизгел» альбомында шактый зур урын бирелүен әйтергә ашыкты.

– Миләүшә Ләбибовна, мин сезгә каршы чыкмыйм. Мин бу турыда әйтергә тиеш. Безнең ветераннарыбызның исемнәре яңгырасын, кино тарихын яшьләребез белсен. Үсеп килүче буын татар киносының буш урында тумаганлыгын аңларга тиеш, – диде Илдар Ягъфәров.

Кино тарихында төрле чорлар була. Татарстанның халык артисты Гамил Әсхәдулла, 12 ел кинопрокат өлкәсендә эшләгән кеше буларак, узган гасырның туксанынчы елларында эротик фильмнарга каршы көрәшүләре турында сөйләде.

– Ул вакытта шундый фильмнар күрсәтү тенденциясе бар иде. Бер яктан, фильмны алып киләләр, икенче яктан, күрсәткән өчен хакимият сүгә. Ул чакта прокат системасы шактый камил иде, халыкка яхшы фильмнар күрсәтергә тырыштык. Шулай да, караган кеше эротик фильмнарны да карады. Башта халык чишенгән артист эзләде бит, хәзер киенгәннәре тансык… – дип искә алды ул. – Ул чактагы прокат системасы җитми хәзер. Анда бөтен нәрсә көйләнгән иде. Миләүшә Ләбибовна, менә шул система кирәк безгә. Кино төшерәләр – күрсәтеп булмый. Халык йөрмиме? Оештырылып бетмәгәнме? Сәбәбе нидә икән?

Кызганыч, бу сораулар җавапсыз калды. Ә Татарстан өчен театр мөһимрәкме, киномы? Журналистларның бу соравы, аерым алганда, Мәдәният министрлыгына юнәлдерелгән иде. Театр бинаалары яңартылып, төзелеп тора. Театрларга финанс ярдәме бюджетка кертелгән. Ә кинобыз? Мәдәният министрлыгының 10 проектка 8 млн сумны бүлеп бирүенә карап утырып булмас бит…

– Гомумән, ул грант конкурсы финанс ягыннан искергән, – диде бу турыда Илдар Ягъфәров. – Бүген 500 мең сум – бик кечкенә сумма. Хәтта документаль фильм өчен дә. Яшьләр үсә, энтузиазм – мәңгелек әйбер түгел.

Дамир Натфуллин исә финанслауның әлеге конкурс белән генә чикләнмәвен әйтте. «Кайбер фильмнарга өстәмә акчалар да бирелә бит», – диде ул.

Миләүшә Айтуганова исә һәрвакытта да, һәрнәрсәне дә акча хәл итмәвен әйтте. «Фильмның популярлыгы нәрсәгә бәйле? Бу – шулай ук бәхәсле мәсьәлә. Йөзәр миллион сумлык фильмнар да игътибарсыз кала кайчак», – диде ул.

Чыннан да, бу турыда инде күп сөйләнде, әле күпме сөйләнер. Ләкин шунысы бәхәссез: система булдырырга кирәк.

– Бүген шуны эшләмәсәк, киләчәктә фильм төшерү процессы тагын да катлауланачак. Финанс ярдәме мәсьәләсен дә, кайсы юлдан баруыбызны да хәзер уйларга кирәк. Без нәрсәгә нигезләнәчәкбез? Ислам идеологиясенәме? Нинди фильмнар төшерәчәкбез? Ихласмы, заманга яраклаша торганнарнымы? Театрга бәхет елмайды: ул совет заманында туды. Театр бюджеттан финанс ярдәме ала. Кинога да шушыңа килергә вакыт, – диде Илдар Ягъфәров матбугат очрашуы ахырында.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ПӘРДӘ АЧЫЛА

КАМАЛ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕ АРТЫНА СӘЯХӘТ

Мәдәният дөньясында

Театр сәхнәсенең артында ниләр бар икән? Бөтенләй башка чорга, башка мохиткә алып китә торган спектакльләргә декорацияләрне кем ясый? Ә костюмнар кайда саклана? Театрга килгән саен диярлек мине әнә шул сораулар кызыксындыра иде. Сәхнә арты – үзе бер серле дөнья кебек бит ул!

Камал театрының постановка буенча мөдире Илшат ӘМИНОВ, шул дөньяга экскурсия уздырып, кайбер серләрне ачты.

Әйләнә сәхнә, әйләнә

Сәяхәтне Камал театрының зур сәхнәсеннән башладык. Кич куелачак «Тормышмы бу?» спектакленең декорацияләре үз урыннарын алган, утлар көйләнгән, реквизитлар әзер иде инде ул чакта. Илшат Әминов сөйләвенчә, спектакленә карап, сәхнә берничә сәгатьтән алып тулы бер тәүлеккә кадәр көйләнә. Андый-мондый хәлләр килеп чыкмасын өчен, барысы да кат-кат тикшерелә.

– Моннан күп еллар элек тиз арада спектакльне алыштырдылар. Нинди спектакль куеласы булгандыр, ләкин аның урынына «Казан егетләре» булды. Шулай берзаман, егетләр печән эскерте өстендә яткан вакытта, кар ява башламасынмы! Куелырга тиешле спектакльдә кулланыла иде ул, сүндерергә онытылган, – дип искә ала Илшат.

Сәхнәдә чакта төсләр турында сораштым. Әйтик, ни өчен сәхнә бизәлешендә кара төс өстенлек итә? Илшат Әминов аңлатуынча, кара – иң универсаль, игътибарны һәм утны үзенә алмый торган төс. Ә хәзерге спектакльләрдә декорацияләрнең аз булуы – яңа тенденцияме икән?

– Минимализация дисеңме? Анысы режиссердан тора. Бездә юк әле ул. Бервакыт безгә мәскәүлеләр килде. Бер сәгать һәм ике урындык белән спектакль уйнап чыктылар, – ди әңгәмәдәшем.

Декорацияләр саклана торган складның да кайда икәнен күрдем. «Менә монысы – «Рәшә»некеләр, монысы – «Мөһаҗирләр», «Дуслар җыелган җирдә…» – дип санап китте Илшат Әминов. Ул аларның кайсы кайда торуын карамыйча да белә иде бугай…

– Репертуардан төшеп калган спектакль декорацияләрен башка урында саклыйбыз. Алар биш ел тора әле, шуннан соң гына я сүтелә, я кулланыла, я утильләштерелә, – дип аңлатты ул.

Бормалы коридорлар буйлап йөри торгач, эретеп ябыштыру цехына да күз салдык. Ә аннан иң чуар, иң «бай» урынга – костюмнар саклана торган бүлмәгә кердек. Күз алдына китерегез: иң иске костюм 1934 елгы булгач, монда аларның санын исәпләп-чутлап бетерә торган түгелдер… «Аларның санын якынча да әйтә алмыйм», – ди инде 12 ел костюмнар өчен җаваплы Гөлсинә апа Һадиева. «Нинди генә костюмны сорасаң да, күзен йомып таба», – ди аның турында Илшат Әминов.

Мондагы костюмнарның 90 проценты театрдагы тегү цехыннан чыга. Кайбер кием өлешләре сатып алына, ниндидер костюмнар заказ белән башка җирдә тектерелә.

Спектакль герое кулындагы алма, банкасы белән тозлы кыяр, скульптуралар, арыш басулары… Без аларга артык игътибар да итмибез инде. Күпләр аларны чын дип уйлыйдыр. Ә бит аларның барысы да театрның бутафория цехында эшләүче кызларның алтын куллары белән ясала. «Сүнгән йолдызлар»дагы арыш сабакларын хәтерлисезме? 20 меңнән артык булган алар! Һәм һәр арышны аерым ясаганнар. Моның өчен студентлар ярдәме һәм 3 атна вакыт кирәк булган.

kamalteatr.ru

«Сүнгән йолдызлар» спектакленнән.

Моннан тыш, һәр спектакльнең – үз касәсе, үз тәлинкәсе, үз чәйнеге, үз зонтигы, үз таягы… Кыскасы, үз реквизитлары. Аларны туплау – үзе бер маҗара, ди Илшат Әминов. Ә реквизитлар өчен театрда өч кеше җаваплы. Бер генә репетицияне дә калдырмыйлар, спектакль буена бер карандаш кына кирәк булса да, башыннан ахырына кадәр утыралар икән.

«Спектакльләрне тыныч кына карый алмыйм»

Илшат Әминов Камал театрында инде 22 ел эшли. Постановка буенча мөдир вазыйфасына бер еллап элек билгеләнгән, аңа кадәр ут кую өчен җаваплы булган. Белеме буенча – инженер-механик.

– Студент вакытта очраклы гына гади ут куючы булып урнаштым. Урнаштым да, театр җибәрмәде. Театрда эшләрмен дип күз алдына да китермәгән идем, дөресен әйткәндә, – ди әңгәмәдәшем.

Бер сәгатьләп кенә артыннан ияреп йөрсәм дә, эшенең, беренчедән, бик җаваплы, икенчедән, техник яктан да, оештыру җәһәтеннән дә катлаулы булуын аңладым. Театрда эшләгәч, иҗади фикерләү дә кирәк бит әле.

– Без эшне читкаларга кадәр үк башлыйбыз. Рәссам сызган макетка яки ул әйтеп торып, үзебез сызган макетка нигезләнеп эшлибез. Һәр репетицияне карыйбыз, үзгәртәсе урыннарны бергәләп үзгәртәбез, – ди Илшат.

«Эштән тыш театрга йөрисезме?» – дип кызыксынам.

– Йөргәлим. Әмма спектакльләрне тыныч кына карый алмыйм. Бу декорацияне ничек ясадылар икән? Монда ут каян төшә икән? Кич буе әнә шул хакта уйлап утырам, – дип көлә ул.

Постановка өчен җаваплы итеп билгеләнгәч, 4 спектакль чыгарганнар. Сәхнә бизәлеше ягыннан Илшат Әминовның үзенә иң ошый торганы «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (реж. – Фәрит Бикчәнтәев) спектакле икән. «Катлаулылыгы белән ошый ул миңа», – ди Илшат.

* * *

Сәхнә арты серләре моның белән генә бетмәде, билгеле. Ләкин барысын да сөйләсәң, кызыгы калмый аның.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

УН БАЛА АНАСЫ КӘҮСӘРИЯ ИСМӘГЫЙЛЕВА:

«БЕРӘР ЧИЛӘК КАМЫР КУЯ ИДЕМ»

2024 гаилә елы

Арча районының Казанбаш авылында яшәүче 60 яшьлек Кәүсәрия апа Исмәгыйлева ун бала тәрбияләгән. Алар үсеп, кайсы кая таралышкан инде. Хәзерге вакытта янәшәсендә ике кызы – Дилүзәсе белән Алиясе бар. Тәртипле балалар үстергән ана шуны әйтә: «Һәр сорага «җә» дип тормаска!»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Һәр гаиләнең үз тәртибе, кагыйдәләре бар. Исмәгыйлевларныкы хәтта ишектән керүгә үк диварга эленгән.

Анда ак белән караны аерырга өйрәтеп, тегесен яки монысын эшләргә ярамый, дигән әмерләрне күрмисең. Киресенчә, рухи якка күбрәк басым ясалган. 14 баганадан тора ул. Әйтик, бер-береңне кочакларга, үзеңә ышанырга, ялкауланмаска, вәгъдәңне үтәргә, авыр булса да, кичерергә, дөресен сөйләргә… Бер караганда, баштан сыйпап, гел кочаклашып тору авыл кешесенә бик үк хас нәрсә түгел дә кебек. Әмма ун баланың алтысы кыз булуын исәпкә алсак, моңа гаҗәпләнергә кирәкми.

– Моны безгә бүләк иткәннәр иде. Әмма ул безнең гаилә кагыйдәләренә туры килә. Бер-беребезгә карата ягымлы, тәмле телле булырга тырышабыз, – ди 18 яшьлек төпчекләре Алия.

Без килгәндә, Кәүсәрия апа мәрхүм иренең апасы Флера белән кухняда аш-су әзерли иде. Кызганыч, Рөстәме 48 яшьтә дөнья куйган. Бу вакытта Алиягә нибары 4 яшь кенә булган. Балакай әтисен бөтенләй хәтерләми. Әмма каенапа белән элемтәләр өзелмәгән. Арчада фатиры булса да, Флера апа авылда яши.

Кәүсәрия апа ун бармагын бөгә-бөгә ул-кызларының исемнәрен санады башта. Дүртесе үз гаиләсен корган инде. Әйтик, иң олы улы Айрат Кырлайда яши. Аңа – 36 яшь. Икенче улы Ленар – хәрби операциядә. Ялларга да кайтып киткәләгән. Дрон бәреп төшергән өчен, 21 көн өстәмә ял биргәннәр. Яудагы улын искә алмаган сәгате, көне юк ананың. Көтү бик авыр, әмма улының Ватанны саклавы белән горурлана. Ленар әле өйләнмәгән. Өмете – исән-сау кайтып, төп йортта гаилә учагын сүндермәү. Дилүсе Мөндеш авылында төпләнгән. Калганнары – Дилүзә, Азалия, Фирүзә, Билгус, Диләрә, Гөлия һәм Алия. Балалары күбрәк авыл хуҗалыгы, төзелеш, сату өлкәсендә хезмәт куя. Кәүсәрия апа әйтүенчә, нәрсә кушсаң, шуны эшлиләр. Шикәр авыруы булгач, үзе абзарга чыгып йөри алмый икән. Кызлар исә иртүк эшкә, укырга малларны карап китә. Сүз уңаеннан, Кәүсәрия үзе дә 10 нчы сыйныфны тәмамлауга ук фермага эшкә урнашкан. Башта таналар караса, аннан сыер сауган. Балалары да – җир кешеләре. Өч улы да авылда калган – механизаторлар.

– Кыенлыкларын күрмәдем. Балалар йөзебезгә кызыллык китермәде. Авырып борчымадылар, әйбәт укыдылар. Сүземне тыңладылар. Кечкенәдән эшләп үстеләр. Әйбер сорап аптыратмадылар. Берсенең киемен икенчесе киеп үсте. Мал-туар асрагач, алай кыенлык күрмәдек, – ди Кәүсәрия ханым, барысыннан да канәгать калып. – Балалар кайтканда, бүлмәдә булсам, «Әни кайда?» – дип сорый башлыйлар. Ишектән кергәндә, иң беренче сүзләре шул. Сагынып торгач, рәхәт. Мин – кадерле әни.

Балаларның гел башларыннан гына сыпырып торып булмый. Бер тапкыр Диләрә өйгә соңга калып кайткан. «Башка чакта вакытында кайтырсың», – дип, су шлангы белән бераз әләктереп алган Кәүсәрия апа. Бу хатаны башка берсе дә кабатламаган. Әйберләрен тәртипләп куярга өйрәткән. Киемнәрен таба алмаганда, «Мин тимәдем», – дип, эзләргә булышмаган. Икенче көнне тәртип белән элеп куйганнар.

Унысында – ун төрле холык. Арада Фирүзә таләпчән булуы белән аерылып торган. Анысын күршеләре, шаяртып, «финанс министры» дип йөрткән. Балаларның берәрсе: «Әни, бер сүз генә әйтим әле», – дип колагына пышылдый башласа, Фирүзә аны шундук туктаткан: «Әнидән бер әйбер дә сорыйсы түгел, аның болай да акчасы юк!» Хәзер ул Казанда кибетче булып эшли.

Замана әти-әниләренә, балалар көен генә көйләп тормаска, мөстәкыйльлеккә өйрәтергә киңәш итә Кәүсәрия апа. Оныкларын да иркәләү ягында түгел.

> Оныклар кунакка килгәч, русча сөйләшә башлый. Хәзер авылда да шулай бит. «Мин русча белмим, татарча әйтегез. Алайса, сезне күршедәге Сашкага кертеп куям», – дип кисәтәм.

Шып туктыйлар. «Ашамыйбыз», – дип киреләнә башласалар, көйләп утырмыйм. «Хәзер киенерсез дә өегезгә төшереп куярбыз. Ашамаган кешеләрне үзебездә тотмыйм», – дим. «Әйдә, бүл инде алайса», – дип, шыпырт кына табын янына килеп утыралар, – ди ул.

– Өйдә бала күп булгач, чиләге белән камыр куярга, икешәр кәстрүл аш пешерергә туры килгәндер? – дип сорыйм Кәүсәрия ападан.

Бу урында ул каенанасы Сараның сүзләрен искә төшерде. Ул: «Булса туярлык, калганын җыеп куярлык булсын», – дияргә яраткан. Ире Рөстәм гаиләдә иң төпчеге – унберенчесе булган. Кәүсәрия апа да ризыкны мулдан әзерләгән.

Бергә җыелышканда, Исмәгыйлевларның өйләре гөрләп тора. Иң күңелле чак – шул.

– Әниебез бик әйбәт. Аның беркайчан да ачуланганы юк. Бөтенебезне тигез күрде, кадерләп үстерде. Ун баланы тәрбияләп үстерү өчен бик зур сабырлык кирәк. Ул безнең өчен – Герой-ана, – ди Алия.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 226

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+